| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.07.2017 г. Казань № 344-пр

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә эшкә алучының вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибе турында

2004 елның 27 июлендә кабул ителгән 79-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында» Федераль законның 17 статьясының 1 өлешендәге 3 пункт нигезендә б о е р а м:

1. Тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә эшкә алучының вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашырга яки идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне үземдә калдырам.

**Министр** **А.К.Хамаев**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 21.07.2017
№ 344-пр номерлы карары белән расланды

## Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә эшкә алучының вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идерә итүдә катнашырга яки идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибе

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә эшкә алучының вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идерә итүдә катнашырга яки идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибен (алга таба – Тәртип) 2004 елның 27 июлендә кабул ителгән 79-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләт гражданлык хезмәте турында» Федераль законның 17 статьясының 1 өлешендәге 3 пункт нигезендә эшләп чыгарылган.

Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә (алга таба – граждан хезмәткәрләре) эшкә алучының вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы, күчемсез милек хуҗалары ширкәте (алга таба – коммерциячел булмаган оешма) белән идарә итүдә катнашырга яки идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү процедурасын көйли.

Әлеге Тәртип эшкә алучысы булып Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры (алга таба – министр) торган граждан хезмәткәрләренә кагыла.

2. Түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмаларның идарәсендә катнашырга яки идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү турында

гариза (алга таба – Гариза) граждан хезмәткәре тарафыннан язма рәвештә әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасына карап тутырыла.

3. Граждан хезмәткәре Гаризаны коррупцион һәм башка төр хокук бозуларны кисәтү буенча җаваплы булган вазыйфаи затка (алга таба – Вазыйфаи зат) тапшыра.

4. Вазыйфаи зат Гаризаны килгән көнне үк әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасында бирелгән форма буенча Журналда терки.

5. Вазыйфаи зат Гаризаны беренчел карап чыга һәм шул нәтиҗә буенча бәяләмә әзерли.

Гаризаны беренчел карау барышында Вазыйфаи зат Гариза тапшырган граждан хезмәткәреннән күздә тотылган коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуның функцияләрен билгели торган документлар язмача һәм аңлатмалар сорарга хокуклы.

Бәяләмә граждан хезмәткәренә түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмаларның идарәсендә катнашырга яки идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү яки баш тарту турында тәкъдимне үз эченә алырга тиеш.

6. Гариза теркәлгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча, Вазыйфаи зат бәяләмә һәм башка материаллар (булган очракта) теркәлгән Гаризаны карау һәм дәүләт гражданлык хезмәткәренә эшкә алучының вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмаларның идарәсендә катнашырга яки идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итү яки баш тарту турында карар кабул итү өчен министрга (аның вазыйфаларын башкаручы затка) бирә.

Министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) Гаризаны алган көннән башлап ике эш көне дәвамында карар кабул итә.

7. Вазыйфаи зат министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) карар кабул иткән көннән башлап ике эш көне дәвамында граждан хезмәткәренә Гаризаны карау нәтиҗәләре турында хәбәр итә һәм министр резолюциясе белән булган Гаризаның Министрлыкның кадрлар бүлеге мөһере белән расланган күчермәсен кул куйдыртып тапшыра. Гаризаның министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) резолюциясе булган төп нөсхәсе граждан хезмәткәренең шәхси эшенә теркәп куела.

Татарстан Республикасы Җир һәм
мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында
Татарстан Республикасы дәүләт граждан

хезмәткәренә эшкә алучының вәкиле
тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер
башкарма орган сыйфатында
коммерциячел булмаган оешмалар белән
идерә итүдә катнашырга яки
идарәләренең коллегиаль органнары
составына керергә рөхсәт бирү
тәртибенә
1нче кушымта

Республики Татарстан
Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт
мөнәсәбәтләре министрына
_______________________________________
_______________________________
(Ф.И.ӘИ (соңгысы – булганда), биләгән вазыйфасы
һәм структур бүлекчәсе,
_______________________________________
_______________________________
яшәү урыны адресы
__________________________________
телефон номеры)

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә эшкә алучының вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идерә итүдә катнашырга яки идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт бирү турында

Гариза

Миңа түләүсез нигездә_____________________________________________
(бердәнбер башкарма орган яки идарәнең коллегиаль органы атамасы)
____________________________________________________________сыйфатында
(кирәгенең астына сызарга)
______________________________________________________________________
(иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык,
______________________________________________________________________
яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы, күчемсез милек хуҗалары ширкәте) идарәсендә катнашырга, идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт итүегезне сорыйм.

_____________ ___________________ __________________
(дата) (имза) (фамилия, инициаллар)

Татарстан Республикасы Җир һәм
мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында
Татарстан Республикасы дәүләт граждан
хезмәткәренә эшкә алучының вәкиле
тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер
башкарма орган сыйфатында
коммерциячел булмаган оешмалар белән
идерә итүдә катнашырга яки
идарәләренең коллегиаль органнары
составына керергә рөхсәт бирү
тәртибенә
2нче кушымта

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә эшкә алучының вәкиле тарафыннан түләүсез нигездә бердәнбер башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар белән идерә итүдә катнашырга яки идарәләренең коллегиаль органнары составына керергә рөхсәт бирү турында гаризаларны теркәү
ЖУРНАЛЫ

| № п/п | Дата | Ф.И.Ә. (соңгысы - булганда), гариза бирүченең вазыйфасы | Гариза бирүченең имзасы | Регистраторның Ф.И.ӘИ. (соңгысы - булганда) | Регистраторның имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |